ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 159-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 159-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2026 елның 19 феврале
№ 548-VII ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»
Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына
үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8-9; 2016, № 1-2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 74 (I өлеш), № 93) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 19 һәм 20 пунктларны өстәргә:

«19) гомуми файдаланудагы төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларына, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына, гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юлларына һәм күрсәтелгән автомобиль юлларының аерылгысыз технологик өлеше булып торучы, концессия килешүләре нигезендә яисә йөкләмәләрне үтәү Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре белән тәэмин ителгән заем шартнамәсе буенча алынган акчалардан файдаланып булдырылган һәм 2024 елның 1 декабреннән 2025 елның 31 декабренә кадәр файдалануга кертелгән корылмаларга карата. Гомуми файдаланудагы төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларының, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының, гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юлларының аерылгысыз технологик өлеше булган корылмаларга карый

торган мөлкәт исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Салым ташламасы объект файдалануга кертелгән айның 1 числосыннан башлап, җиде елга бирелә;

20) Россия Федерациясендә социаль, икътисадый, демографик, экологик һәм башка иҗтимагый процесслар турында рәсми статистик мәгълүмат булдыру функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы белешмәләре буенча халык саны 7 мең кешегә кадәр булган шәһәрләрдә урнашкан, югары белем бирү мәгариф оешмалары тарафыннан файдаланыла торган уку-лаборатория корпуслары булып торган объектларга карата.»;

2) 5 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 16 пунктны өстәргә:

«16) 2029 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 20 пунктын.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 19 пункты нигезләмәләренең (әлеге Закон редакциясендә) гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 20 пункты нигезләмәләренең (әлеге Закон редакциясендә) гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына**
**үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы закон проектына**
**АҢЛАТМА**

Россия Федерациясе Салым кодексының 372 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацы нигезендә оешмалар мөлкәтенә салым билгеләгәндә Россия Федерациясе субъектлары законнары белән салым ташламалары, салым түләүчеләр тарафыннан аларны куллану нигезләре һәм тәртибе каралырга мөмкин.

Закон проекты гомуми файдаланудагы төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын, гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юлларын һәм күрсәтелгән автомобиль юлларының аерылгысыз технологик өлеше булып торучы, концессия килешүләре нигезендә яисә йөкләмәләрне үтәү Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре белән тәэмин ителгән заем шартнамәсе буенча алынган акчалардан файдаланып булдырылган корылмаларны һәм Иннополис шәһәренең белем бирү инфраструктурасын төзүгә һәм алардан файдалануга юнәлдерелгән инвестиция проектларына салым йөкләнешен киметү максатыннан эшләнгән.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасы территориясендә концессион килешүләр кысаларында төзелгән ике объект: «Вознесенск тракты. Казан шәһәре Совет районында һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында Җиңү проспектыннан алып «Волга» М-7 автомобиль юлына кадәр түләүле юл төзелеше» һәм «Казан-Оренбург» федераль автомобиль юлының яңа маршрутын үстерү максатында Шәле (М-7) - Баулы (М-5) түләүле автомагистрален төзү кысаларында Алексеевск - Әлмәт автомобиль юлын төзү». Ташламалар тәэсиренә шулай ук алар буенча йөкләмәләрне үтәү Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре белән тәэмин ителгән займ шартнамәсе буенча алынган акчалардан файдаланып төзелгән ике автомобиль юлы инфраструктурасы эләгә: «Йошкар-Ола - Зеленодольск» юлыннан Казан шәһәре чигенә кадәрге автомобиль юлы һәм «Горький шоссесының реконструкцияләнә торган участогы».

Оешмалар мөлкәтенә салым буенча күздә тотыла торган ташламага югары белем бирү мәгариф оешмалары файдалана торган укыту-лаборатория корпуслары булып торган объектларга нисбәттә Иннополис шәһәре территориясендә урнашкан объектлар эләгә.

Закон чыгару инициативасы автомобиль юллары төзелеше өлкәсендә республиканың инвестицияләр җәлеп итүчәнлеген арттыруга, эксплуатацияләү стадиясендә оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсацияләнә торган чыгымнарны киметүгә, автомобиль юлларының түләүле участокларында йөргән өчен уңайлы бәяләрне тәэмин итүгә, шулай ук Иннополис шәһәренең мәгариф һәм фәнни базасын үстерүгә һәм Татарстанның IT-кластерын ныгытуга юнәлдерелгән.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына**
**үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын**
**кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып**
**торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан**
**Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының гомуми файдаланудагы төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларының, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының, гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юлларының аерылгысыз технологик өлеше булган корылмаларга карый торган мөлкәт исемлеген раслый торган норматив хокукый актын кабул итүне таләп итә.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»
Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына
үзгәрешләр кертү хакында»
Татарстан Республикасы закон проектын**

# ФИНАНС- ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы нигезендә салым преференцияләре күләме гомуми файдаланудагы төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юллары, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары, гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юллары һәм күрсәтелгән автомобиль юлларының аерылгысыз технологик өлеше булган корылмалар өлешендә - 7 ел дәвамында 13,7 млрд сум, югары белем бирү оешмалары файдалана торган укыту-лаборатория корпуслары булып торучы объектларга мөнәсәбәттә - 2026-2028 елларда 103 млн сум тирәсе тәшкил итә.